**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10342**
**27.10.2023**

Башкарма комитетның 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 15 пунктчасы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы Карары (Башкарма комитетның 2017 елның 17 апрелендәге 2289 номерлы, 2021 елның 29 гыйнварындагы 543 номерлы, 2023 елның 15 маендагы 3927 номерлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

«Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамәдә билгеләнгән мәйдан чикләрендә, җәмәгать туклануы объектларыннан тыш, стационар булмаган сәүдә объекты янында проектта каралмаган өстәмә җиһаз (суыткыч витриналар, лотоклар, товар кую һәм саклау өчен кулланыла торган башка җиһаз) урнаштыру, шулай ук стационар булмаган сәүдә объектлары янында өстәлләр, зонтиклар кую рөхсәт ителми.»;

2) 12 пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

«Төзекләндерү элементларында һәм стационар булмаган сәүдә объектына чиктәш территориядә товар, төрү материаллары, чүп өеп куюны гамәлгә ашыру тыела.»;

3) 13 пунктта 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) торак йортлар, биналар тәрәзәләреннән, стационар сәүдә объектлары витриналарыннан 20 метрдан ким ераклыкта бина аркаларында, чәчәк

түтәлләрендә, балалар мәйданчыкларында, ял мәйданчыкларында, спорт мәйданчыкларында;»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 13.1 пункт өстәргә:

«13.1. Стационар булмаган сәүдә объектларын, стационар булмаган сәүдә объекты чикләреннән чыкмаган, объектның киңлегенә һәм озынлыгына параллель урнашкан, биеклеге 5 сантиметрдан артмаган тимер-бетон балкалардан торган нигездә, газонга урнаштырырга рөхсәт ителә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов